**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.02.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№42-07

Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында» 2016 елның 23 ноябрендәге 11-07 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендәге 444-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында» 2016 елның 23 ноябрендәге 11-07 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 7 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1_1 пунктчасы өстәргә:

«1_1. 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән объектка карата, әгәр мондый объект килешү төзелү вакытына Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкарь) яисә ачыкланган мәдәни мирас объекты булса, килешү төзү рөхсәт ителми.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов